КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 июнь г.Казань № 405

«Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик кушу)» максатчан моделен гамәлгә кертү буенча «юл картасы» чаралары планын раслау турында

Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинның 2016 елның 5 декабрендәге Пр-2347ГС номерлы йөкләмәләре исемлегенең 3 пунктын, Россия Федерациясе Хөкүмәте Аппараты раслаган 2017 елның 31 гыйнварындагы 717п-П13 номерлы Россия Федерациясе федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Россия Федерациясе башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе субъектларында максатчан модельләрне кертү һәм максатчан модельләрдә билгеләнгән күрсәткечләргә ирешүне бәяләү критерийләрен формалаштыру буенча методик тәкъдимнәрне үтәү өчен, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 ел, 31 гыйнвар, 147-р боерыгы белән расланган «Газ бүлү челтәрләренә тоташу (технологик кушу)» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча эшне оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлә торган «Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик кушу)» максатчан моделен гамәлгә кертү буенча «юл картасы» (алга таба – «юл картасы») чаралары планын расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ һәм «Газпром төбәкарагаз Казан» АҖ тәкъдим итәргә, «юл картасын» тормышка ашыруны һәм хисап чорыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр, ай саен, «юл картасын» тормышка ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына хисап чорыннан соң килә торган айның 1 есенә кадәр, ай саен:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «юл картасын» тормышка ашыру барышы турында җыелма хисап бирергә;

«Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик кушу)» максатчан моделе күрсәткечләренең агымдагы мәгънәләрен Region-id мәгълүмат системасына кертүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\405.docx